**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Об утверждении Положения о Полномочном представительстве Республики Татарстан в Туркменистане

В целях совершенствования деятельности Полномочного представительства Республики Татарстан в Туркменистане, в соответствии с Конституцией Республики Татарстан и Законом Республики Татарстан от 10 ноября 2003 года № 47-ЗРТ «О представительствах Республики Татарстан» **постановляю:**

1. Утвердить прилагаемое Положение о Полномочном представительстве Республики Татарстан в Туркменистане.

2. Признать утратившим силу пункт 2 Указа Президента Республики Татарстан от 11 августа 2009 года № УП-421 «Об учреждении Полномочного представительства Республики Татарстан в Туркменистане».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
16 октября 2026 года
№ 857

УТВЕРЖДЕНО
Указом Раиса
Республики Татарстан

от « 16 » октября 2026 года

№ 857

# ПОЛОЖЕНИЕ
# о Полномочном представительстве Республики Татарстан в Туркменистане

## I. Общие положения

1. Настоящее Положение определяет основы деятельности Полномочного представительства Республики Татарстан в Туркменистане (далее – Представительство), его правовой статус, цели, задачи и функции.

2. Представительство осуществляет свою деятельность в соответствии с Конституцией Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законодательством Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан, законодательством Туркменистана, а также настоящим Положением.

3. Представительство является постоянно действующим государственным органом Республики Татарстан, осуществляющим деятельность по обеспечению торгово-экономических, научно-технических, культурных, гуманитарных и иных связей Республики Татарстан с Туркменистаном.

4. Представительство является юридическим лицом, имеет печать с изображением Государственного герба Республики Татарстан и со своим наименованием, счета, открываемые в установленном законодательством порядке.

5. Представительство использует государственную символику Республики Татарстан в порядке, установленном законодательством Республики Татарстан.

6. Местонахождение Представительства – г. Ашхабад, Туркменистан.

## II. Цели, задачи, функции Представительства

7. Целью Представительства является содействие установлению, развитию и расширению торгово-экономических, научно-технических, культурных, гуманитарных и иных связей между Республикой Татарстан и Туркменистаном.

8. Задачи Представительства:

представление интересов Республики Татарстан по вопросам, касающимся торговли, финансово-кредитной деятельности, инвестиций, науки, культуры, туризма и других видов экономической и гуманитарной деятельности, не затрагивающим компетенцию Российской Федерации;

содействие организациям, расположенным на территории Республики Татарстан и Туркменистана, в области торговли, научно-технического, экономического и гуманитарного сотрудничества.

9. Функции Представительства:

содействие развитию внешних связей Республики Татарстан с Туркменистаном в торгово-экономической, научно-технической, экологической, гуманитарной, культурной и иных областях;

представление Республики Татарстан на двусторонних и многосторонних переговорах, совещаниях, конференциях, симпозиумах и конгрессах, представляющих интерес для Республики Татарстан;

участие в подготовке проектов соглашений Республики Татарстан об осуществлении международных и внешнеэкономических связей, договоров (соглашений) между органами государственной власти Республики Татарстан, федеральными органами государственной власти, органами государственной власти Туркменистана, разработке предложений и переговорах по заключению таких договоров и соглашений, а также осуществление наблюдения за их исполнением;

осуществление анализа состояния и основных тенденций развития сотрудничества в рамках заключенных Республикой Татарстан договоров и соглашений;

содействие установлению прямых хозяйственных связей, созданию совместных организаций и других возможных совместных форм сотрудничества в экономической, финансовой и гуманитарной областях;

оказание справочно-информационных и консультативно-методических услуг, касающихся Республики Татарстан, ее политической, социально-экономической, культурной и духовной жизни;

участие в подготовке и организации визитов официальных делегаций Республики Татарстан в Туркменистан;

поддержание связи с татарами, проживающими в Туркменистане, оказание им содействия в развитии национальной культуры, языка, сохранении самобытности;

поддержание сотрудничества организаций, общественных объединений, расположенных на территории Республики Татарстан, с организациями, общественными объединениями, расположенными на территории Туркменистана, в рамках осуществления культурных, научных, образовательных и иных связей;

иные функции, соответствующие целям и задачам Представительства.

## III. Права и обязанности Представительства

10. Представительство:

участвует по согласованию с соответствующими республиканскими органами исполнительной власти и организациями в переговорах и работе делегаций Республики Татарстан, находящихся в служебных командировках в Туркменистане;

взаимодействует и осуществляет координацию своей деятельности с Посольством Российской Федерации в Туркменистане и Торговым представительством Российской Федерации в Туркменистане;

содействует организации различного рода выставок, ярмарок, способствующих развитию торгово-экономических, научных и культурных связей Республики Татарстан с Туркменистаном, и участвует в них.

## IV. Руководство деятельностью Представительства

11. Представительство возглавляет руководитель Представительства – Полномочный представитель Республики Татарстан в Туркменистане (далее – Представитель), который назначается на должность и освобождается от должности Раисом Республики Татарстан. Представитель назначается на должность сроком на три года. Одно и то же лицо может быть назначено на должность Представителя неоднократно.

12. Представитель:

осуществляет руководство работой Представительства и несет ответственность за выполнение задач, возложенных на Представительство;

представляет Представительство в отношениях с государственными органами, организациями и гражданами Туркменистана и Российской Федерации;

запрашивает и получает от органов государственной власти Республики Татарстан информацию и материалы, необходимые для осуществления своей деятельности;

согласовывает кандидатуры на должности государственной гражданской службы Республики Татарстан в Представительстве с Администрацией Раиса Республики Татарстан;

принимает на работу и увольняет с работы работников Представительства в соответствии с законодательством и настоящим Положением;

осуществляет взаимодействие с Посольством Российской Федерации в Туркменистане и Торговым представительством Российской Федерации в Туркменистане;

командирует работников Представительства для осуществления деятельности Представительства;

заключает договоры и соглашения в пределах компетенции Представительства;

выдает доверенности;

издает приказы и распоряжения;

распоряжается финансовыми средствами в соответствии с утвержденной сметой.

## V. Обеспечение деятельности Представительства

13. Финансовое и материально-техническое обеспечение деятельности Представительства осуществляется за счет средств бюджета Республики Татарстан и иных источников, не противоречащих законодательству.

14. Имущество Представительства является собственностью Республики Татарстан и закрепляется за ним на праве оперативного управления.

15. Структура, штатное расписание Представительства утверждаются Кабинетом Министров Республики Татарстан по согласованию с Раисом Республики Татарстан.

## VI. Реорганизация и упразднение Представительства

16. Реорганизация и упразднение Представительства производятся по решению Раиса Республики Татарстан.

17. Упразднение Представительства влечет за собой его ликвидацию как юридического лица в порядке, установленном гражданским законодательством.

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының Төрекмәнстандагы вәкаләтле вәкиллеге турында нигезләмәне раслау хакында**

Татарстан Республикасының Төрекмәнстандагы вәкаләтле вәкиллеге эшчәнлеген камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» 2003 елның 10 ноябрендәге 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының Төрекмәнстандагы вәкаләтле вәкиллеге турында нигезләмәне (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Төрекмәнстандагы Тулы вәкаләтле вәкиллеген оештыру турында» 2009 елның 11 августындагы ПУ-421 номерлы Указының 2 нче пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 16 октябрь
№ 857

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «16» октябрендәге
857 номерлы Указы белән
РАСЛАНДЫ

**Татарстан Республикасының Төрекмәнстандагы вәкаләтле вәкиллеге турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасының Төрекмәнстандагы вәкаләтле вәкиллеге (алга таба – Вәкиллек) эшчәнлегенең нигезләре, аның хокукый статусы, максатлары, бурычлары һәм функцияләре билгеләнә.
2. Вәкиллек Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, Төрекмәнстан законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.
3. Вәкиллек – Татарстан Республикасының Төрекмәнстан белән сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәдәни, гуманитар һәм башка элемтәләрен тәэмин итү эшчәнлеген башкара торган Татарстан Республикасының даими гамәлдәге дәүләт органы.
4. Вәкиллек юридик зат булып тора, аның Татарстан Республикасы Дәүләт гербы төшерелгән һәм үз атамасы язылган мөһере, законнарда билгеләнгән тәртиптә ачыла торган счетлары бар.
5. Вәкиллек Татарстан Республикасы дәүләт символларыннан Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә файдалана.
6. Вәкиллек урнашкан урын – Ашхабад шәһәре, Төрекмәнстан.

II. Вәкиллекнең максатлары, бурычлары, функцияләре

7. Вәкиллекнең максаты – Татарстан Республикасы һәм Төрекмәнстан арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәдәни, гуманитар һәм башка элемтәләрне урнаштыруга, үстерүгә һәм киңәйтүгә ярдәм итү.
8. Вәкиллекнең бурычлары:

сәүдә, финанс-кредит эшчәнлеге, инвестицияләр, фән, мәдәният, туристлык һәм икътисадый һәм гуманитар эшчәнлекнең башка төрләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен күздә тотып эш йөртү;

Татарстан Республикасы һәм Төрекмәнстан территориясендә урнашкан оешмаларга сәүдә, фәнни-техник, икътисадый һәм гуманитар хезмәттәшлек өлкәсендә ярдәм күрсәтү.

9. Вәкиллекнең функцияләре:

Татарстан Республикасының Төрекмәнстан белән сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, экологик, гуманитар, мәдәни һәм башка өлкәләрдә тышкы элемтәләрен үстерүгә ярдәм итү;

Татарстан Республикасын кызыксындыручы ике яклы һәм күп яклы сөйләшүләрдә, киңәшмәләрдә, конференцияләрдә, симпозиумнарда һәм конгрессларда Татарстан Республикасы исеменнән эш йөртү;

халыкара һәм тышкы икътисадый багланышларны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы килешүләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль дәүләт хакимияте органнары, Төрекмәнстан дәүләт хакимияте органнары арасындагы шартнамәләр (килешүләр) проектларын әзерләүдә, мондый шартнамәләр һәм килешүләр төзү буенча тәкъдимнәр әзерләүдә һәм сөйләшүләрдә катнашу, шулай ук аларның үтәлешен күзәтеп тору;

Татарстан Республикасы төзегән шартнамәләр һәм килешүләр кысаларында хезмәттәшлекнең үсеше торышын һәм төп тенденцияләрен анализлауны башкару;

турыдан-туры хуҗалык багланышларын урнаштыруга, уртак оешмалар һәм икътисад, финанс өлкәсендә һәм гуманитар өлкәдә хезмәттәшлекнең мөмкин булган башка уртак рәвешләрен булдыруга ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы турында, аның сәяси, социаль-икътисадый, мәдәни һәм рухи тормышы турында белешмә-мәгълүмат һәм консультатив-методик хезмәтләр күрсәтү;

Татарстан Республикасының рәсми делегацияләренең Төрекмәнстанга визитларын әзерләүдә һәм оештыруда катнашу;

Төрекмәнстанда яшәүче татарлар белән элемтәләрне ныгыту, аларга милли мәдәниятне, телне үстерүдә, үзенчәлекләрен саклап калуда ярдәм күрсәтү;

мәдәни, фәнни, мәгариф өлкәсендәге һәм башка элемтәләрне гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең Төрекмәнстан территориясендә урнашкан оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр белән хезмәттәшлеген ныгыту;

Вәкиллекнең максатларына һәм бурычларына туры килә торган башка функцияләр.

## III. Вәкиллекнең хокуклары һәм бурычлары

10. Вәкиллек:

республиканың тиешле башкарма хакимият органнары һәм оешмалары белән килештереп, Төрекмәнстанга хезмәт командировкасына килгән Татарстан Республикасы делегацияләренең сөйләшүләрендә һәм эшендә катнаша;

Россия Федерациясенең Төрекмәнстандагы илчелеге һәм Россия Федерациясенең Төрекмәнстандагы сәүдә вәкиллеге белән хезмәттәшлек итә һәм үз эшчәнлеген алар белән килештерә;

Татарстан Республикасының Төрекмәнстан белән сәүдә-икътисадый, фәнни һәм мәдәни элемтәләрен үстерүгә этәргеч бирүче төрле рәвештәге күргәзмәләр, ярминкәләр оештыруга ярдәм итә һәм аларда катнаша.

## IV. Вәкиллек эшчәнлегенә җитәкчелек итү

11. Вәкиллеккә Вәкиллек җитәкчесе – Татарстан Республикасының Төрекмәнстандагы вәкаләтле вәкиле (алга таба – Вәкил) җитәкчелек итә, аны Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфага билгеләп куя һәм вазыйфадан азат итә. Вәкил вазыйфага өч елга билгеләп куела. Бер үк зат Вәкил вазыйфасына берничә тапкыр билгеләп куела ала.

12. Вәкил:

Вәкиллек эшенә җитәкчелек итә һәм Вәкиллеккә йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен җаваплы була;

Төрекмәнстан һәм Россия Федерациясе дәүләт органнары, оешмалары һәм гражданнары белән мөнәсәбәтләрдә Вәкиллек исеменнән эш итә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны һәм материалларны сората һәм ала;

Вәкиллектәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына кандидатураларны Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе белән килештерә;

законнарга һәм әлеге Нигезләмәгә таянып Вәкиллек хезмәткәрләрен эшкә ала һәм эштән азат итә;

Россия Федерациясенең Төрекмәнстандагы илчелеге һәм Россия Федерациясенең Төрекмәнстандагы сәүдә вәкиллеге белән хезмәттәшлек итә;

Вәкиллекнең эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен Вәкиллек хезмәткәрләрен командировкага юллый;

Вәкиллек компетенцияләре кысаларында шартнамәләр һәм килешүләр төзи;

ышанычнамәләр бирә;

карарлар һәм боерыклар чыгара;

расланган смета нигезендә финанс чаралары белән эш итә.

## V. Вәкиллек эшчәнлеген тәэмин итү

13. Вәкиллек эшчәнлеген финанслар белән һәм матди-техник тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджеты һәм законнарга каршы килми торган башка чыганаклар акчалары хисабыннан башкарыла.

14. Вәкиллекнең мөлкәте Татарстан Республикасы милке булып тора һәм аңа оператив идарә хокукында бирелә.

15. Вәкиллекнең структурасы, штат расписаниесе Татарстан Республикасы Рәисе белән килештереп Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

## VI. Вәкиллекне үзгәртеп кору һәм аның эшчәнлеген туктату

16. Вәкиллекне үзгәртеп кору һәм аның эшчәнлеген туктату Татарстан Республикасы Рәисе карары нигезендә башкарыла.

17. Вәкиллекнең эшчәнлеген туктату аның юридик зат буларак граждан законнарында каралган тәртиптә юкка чыгарылуына китерә.